**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 9 февралендәге 366 номерлы карары**

**Казан шәһәренең Совет районында**
**ачык сервитут билгеләү турында**

1. Әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә ачык сервитут билгеләргә:

1.1. билгеләнә торган ачык сервитут характеристикасы:

- йогынты ясала торган өлкә мәйданы – 51982 кв.м;

- хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номерлары – 16:33:000000:3549, 16:33:140411:16, 16:33:000000:3550, 16:33:140411:23;

- урнашу урыны: Казан шәһәре, Совет районы;

- билгеләү максаты: җәяү һәм транспортта узуны тәэмин итү өчен;

- билгеләү вакыты: вакыты чикләнмәгән;

1.2. гариза бирүче: «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Совет районы администрациясе» муниципаль казна учреждениесе;

1.3. билгеләү өчен нигезләр: гариза бирүче мөрәҗәгате, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексының 23 статьясы.

2. «Казанны үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарга 1, 2 номерлы кушымталар нигезендә чикләрдә ачык сервитутның йогынты ясау өлкәсе турында тиешле мәгълүмат кертү һәм ачык сервитутны дәүләт теркәвенә алу өчен Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә мөрәҗәгать итүне йөкләргә.

3. Әлеге карарга 2 номерлы кушымтадан кала (хезмәт урынында файдалана торган материал), әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.


4. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты рәисе Р.Г.Галәветдиновка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 9 февралендәге
366 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

## Ачык сервитут йогынты ясый торган өлкә чикләре




| Масштаб: 1:15000<br>Координаталар системасы: МСК-16 | |
|---|---|
| Шартлы билгеләр: | |
| 1 | Яңа ясалган характерлы нокта |
| | Ачык сервитутлар (Проектлана торган) |
| | Җир кишәрлекләре |
| 16:33:140411 | кадастр кварталы |
| 16:33:000000:3549, 16:33:140411:16, 16:33:000000:3550, 16:33:140411:23 | хокуклар чикләнә торган җир кишәрлегенең кадастр номеры |

___________________________________